| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**27.03.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 870** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендәге 2685 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыярый ярдәм итүчеләр (волонтер) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» Федераль законның 31.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 333-ФЗ номерлы Федераль закон , 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2018 елның 21 июнендәге «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы , Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендәге 2685 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыярый ярдәм итүчеләр (волонтер) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибенә(2023 елның 31 гыйнварындагы 149 номерлы карарындагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Хәйрия һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеге түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла: ..»

1.2. 3 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаиләгә, күпбалалыкка ярдәм итү, аны ныгыту һәм яклау, традицион гаилә кыйммәтләрен саклап калу, никах институтын популярлаштыру, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар йорты һәм балалар приюты белән эшләүне күздә тота»;

1.3 3 пунктның егерме өченче абзацында түбәндәге сүзләр өстәргә:

«.., балигъ булмаганнарның һәм балигъ булмаганнарга карата җинаятьләрне кисәтү өчен профилактика эшендә катнашу»;

1.4. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«территорияне төзекләндерү»;

1.5. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Җирле үзидарә органнары 1995 елның 11 августындагы «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 135-ФЗ номерлы Федераль законда, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 7-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, 2018 елның 21 июнендәге «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларында каралган формаларда ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм күрсәтәләр».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru ) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин